**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_____________ № ______

«Актаныш муниципаль районы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 30 апрелендәге ПР-84 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру үзенчәлекләренә карата 1 нче кушымтага үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 27 октябрендәге 1747 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 30 апрелендәге ПР-84 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 15 пунктында «2 нче кушымта» сүзләреннән соң, «әлеге кагыйдәләргә (яшәү урыны буенча җирле үзидарә органына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә)» сүзләрен өстәргә;

1.2. 1 нче кушымтаның 18 пунктында «язмача» сүзләреннән соң «яисә Бердәм портал аша электрон формада» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны инфраструктура үсеше буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.И.Гариповка йөкләргә.

Җитәкче И.И.Габдулхаев